СОВЕТ КУШМАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«08» октябрь 2020 нче ел Кошман авылы № 9

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе һәм нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» 2019 елның 30сентябрендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.7 пунктны түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац белән тулыландырырга:

«муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан инициатив проектларны күрсәтү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гамәлгә ашырыла торган җирлектә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресыбуенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://kushman-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кошман авылы җирлеге Башлыгы** **Л.Р. Сафина**